**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**
**Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең**
**Кузҗак авылы**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№2** **18.11.2022**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Кузҗак авылында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Кузҗак авылы халык җыены карар итте:

1 I төркем инвалидлар; олы яшьтәге ялгыз гражданнар; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; контракт буенча хәрби хезмәт үтүче гражданнар; өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнар һәм аларның гаилә әгъзалары; уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлар; хөкем ителгәннәр; авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, Кузҗак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга :

1) Кузҗак торак пунктының авыл эчендәге юлларны төзекләндерү (транспорт хезмәтләре, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Кузҗак торак пунктының урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү ( лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

3) Кузҗак авылында массакүләм чаралар (авыл көне, Өлкәннәр көне, 9 Май, инвалидлар көне ) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

4) Җәйге чорда Кузҗак торак пунктында территорияне чабу (Беларусь -320.4 маркалы тракторга ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү )

5) Кузҗак торак пунктында юлларны кардан чистарту (Беларусь -320.4 маркалы трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

6) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (биек үскән агачларны кисү);

7) халыкның күпләп ял итү урынын төзекләндерү (төзелеш материаллары алу)

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http:// sarmanovo. tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы А.Н.Габдрахманов